Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

РАСПОРЯЖЕНИЕ БОЕРЫК

______20.03.2024_______ Менделеевск ш. № _____205_____

Җаваплы кешене билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының гадәттән тыш хәлләр буенча комиссиясенең 2024 елның 27 февралендәге 4-24 номерлы «2024 елда Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү территориаль подсистемасының Менделеевск муниципаль звеносының эрегән суларны үткәрү чараларын гамәлгә ашыруга һәм табигый характердагы гадәттән тыш хәлләрнең нәтиҗәләрен булдырмау яки йомшарту буенча чараларга әзерлеге турында" карары нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

БОЕРЫК БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетыннан Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары А.Ф.Исхаковны, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесен Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы территориясендә язгы ташу суларын һәлакәтсез үткәрүгә әзерлек һәм аны үткәрү чараларын оештыру өчен җаваплы итеп билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча беренче урынбасарына (Искаков А.Ф.):

2.1. Язгы ташу суларының тискәре йогынтысына дучар булган территорияләрдә авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләр алып бару өчен кирәкле көч һәм чаралар әзерләргә.

2.2. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы территориясендә кар суларының дәрәҗәсен даими тикшереп торуны тәэмин итәргә.

2.3. Көн саен җитәкчегә район территориясендәге вәзгыять турында хәбәр итәргә.

Җитәкче Р.Р.Искәндәров